ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 ноябрь, 2021 ел № 9/17

2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль
милкен хосусыйлаштыру Фараз планын
(программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) кушымтага нигезләнеп расларга.
2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
9/17 Карарына
кушымта
3 ноябрь, 2021 ел

**2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планы (программасы)**

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру фараз планы (программасы, алга таба – Фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) туры китереп эшләнгән.

2. 2022 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, шәһәр бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлтелгән.

3. Хосусыйлаштыруны Нигезнамәгә туры китереп, законда каралган ысуллар белән башкару күздә тотыла.

2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

4. 2022 елда муниципаль казнада торган һәм муниципаль предприятиеләрдә, учреждениеләрдә файдалануда булмаган күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

5. Хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге түбәнге таблицада күрсәтелгән:

| № | Объект исеме | Урыны | Капиталь төзелеш обьекты мәйданы/ озынлыгы | Җир участогы мәйданы | Керемнәр күләме фаразы мең сум. | Фаразланган хосу-сыйлаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:52:040305:1647 кадастр номерлы гараж | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Р. Беляев проспекты, 2а | 18,5 кв. м. | | 180 | 1 квартал 2022 |
| 2 | 16:52:040101:1503 кадастр номерлы гараж | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, ПГСО «Ралли», гараж №113 | 26,8 кв.м. | | 180 | 1 квартал 2022 |
| 3 | 16:52:020701:179 кадастр номерлы 91 | Татарстан Республикасы, Яр | 3488,9 кв.м. | 4150,0 кв.м. | 52 300 | 3 квартал |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | автомобильгә исәпләнгән җир асты машина кую урыны, 16:52:040301:8423 кадастр номерлы җир участогы белән | Чаллы шәһәре, 59/04 торак йорты районында | | | | 2022 |

6. 2022 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиеләрен хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

7. 2022 елда муниципаль милектә булган акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

8. Шәһәр Советының 2020 елның 17 ноябрендәге 2/5 номерлы Карары белән расланган 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планына (программасына) кертелгән, агымдагы елда хосусыйлаштырылмаган объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

9. Күчемсез милекне хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру шартлары турында, шул исәптән, милекне тартып алу белән бер үк вакытта мондый милекне сатып алучы затка сату башкарылганда, әлеге милек биләгән һәм аннан файдалану өчен зарури булган җир участогын хосусыйлаштыру шартлары турында карар Шәһәр Советы Карарлары нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

10. 2022 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлегенә Фараз планының гамәлдәге вакытында Шәһәр Советы Карарлары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.